**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Сатмыш авыл җирлегенең Җиде Кизләү авылында 2020 елның 27 июлендәге**
**«Гражданнарның үзара салым акчаларын күчерү һәм алардан файдалану турында»**

## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

2020 ел, 27 июль №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 27 июлендә булган Җиде Кизләү авылы гражданнары җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзеде: «Җиде Кизләү авылында чишмәне ремонтлау өчен каралган 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын вак таш өслек кулланып автомобиль юлларын ремонтлауга һәм авылның Шоссе урамы буенча җирле әһәмияттәге юлларны карап тотуга күчерүгә, сез ризамы?»

«ӘЙЕ» «ЮК».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенында сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 43 кеше, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар санына 24 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

җыенда катнашкан 24 кеше «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәгечә карар итте:

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы составына керүче Сатмыш авыл җирлегенең Җиде Кизләү авылында халык җыенын узган дип, Халык җыенының нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2.«Җиде Кизләү авылында чишмәне ремонтлау өчен каралган 2020 елда гражданнарның үзара салым акчаларын вак таш өслек кулланып автомобиль юлларын ремонтлауга һәм авылның Шоссе урамы буенча җирле әһәмияттәге юлларны карап тотуга күчерүгә, сез риза мы?» дигән сорау буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3.Гражданнар Җыенының нәтиҗәләрен мәгълүмат стендында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында игълан итәргә.

**Сатмыш Авыл Җирлеге Башлыгы** **Р.Р. Сибгатова**